АВЫЛ ЙОКЛЫЙМЫ?
Саланың кышкы тормышы
> 2

ИНДУС ТАҺИРОВ:
«Путин Шәймиевне юл күрсәтүче пионер дип бәяләде»
> 3



МӘХӘББӘТ БУРАННАРЫ
Республикада өйләнешүчеләр дә, аерылышучылар да арткан
> 3

ЙӨРӘК ЯРАСЫ
булмасын: ел саен Россиядә 30 меңнән артык бала югала
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 6 (28779) | Сишәмбе | 18 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

АРТТЫ, ТИК КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК ТҮГЕЛ

ХУҖАЛЫКЛАРДАН СӨТНЕ НИЧӘ СУМНАН ҖЫЯЛАР?

Актуаль тема

Кышын шәхси хуҗалыкларда сөт күләме кими, ә бәясе арта гадәттә. Декабрь – февраль айларында халыктан җыеп алына торган сөткә бәя югарырак була. Алдагы еллар белән чагыштырганда, быел шактый гына яхшы бәя куелса да, терлек азыгын кыйммәт бәядән юнәтүне искә алсаң, барыбер арзан чыга, ди халык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кукмара районының Бакча-Сарай авылында терлекләрне күп асрыйлар. Һәр хуҗалыкта ким дигәндә 5–6 сыер тоталар, чөнки халыкның барысы да диярлек төп табышны сөт сатып ала. Биредә декабрь ае өчен сөтнең бер литрына 26 сум биргәннәр.

– Сөт җыючы вакытында түләп бара. Без инде узган айның түләвен иртәрәк, 30 декабрьдә үк алдык. Киләсе түләү февраль башында булачак. Бәясеннән без канәгать. Авылда да зарланучыларны ишеткән юк. Күрше-тирә авылларда да шул хак, дип беләбез, – диде Чулпан Һадиева.

Балык Бистәсе районының Олы Елга авылы фермеры Миңзөфәр Исмәгыйлевнең сөт заводы бар. Эшмәкәр 12 авыл халкыннан сөт җыеп эшкәртә.

– Халыктан җыя торган сөтнең сыйфаты шактый аерыла. Берсе су куша, икенчесе өстендәге маен җыеп ала, өченчесенеке ачыган була, дүртенчесенекендә антибиотик табыла. Шуңа күрә бер генә бәя куеп түләү дөрес булмас иде. Алда санап киткән бәяләмәләргә таянып, сөтнең бер литрына 25 сумнан алып 27 сумга кадәр түлибез. Еш кына вак-төяккә күз йомып, яхшы бәя бирергә тырышабыз, – ди фермер.

Миңзөфәр Исмәгыйлев әйтүенчә, районда соңгы бер ел эчендә сыер асраучылар саны бермә-бер кимегән. Алар йортлап түгел, авыллап бетә, ди ул.

– Без башка районнардагы сөт җыючылар белән дә элемтәдә. Алар да шундый ук фикердә тора. Халыкта сөт аз һәм сыйфатсыз булганлыктан, кооператив оештырдык та инде без. Башка районнарда литрына 23, 24 сум түләүчеләр дә бар. Быел бәяләрне арттырсалар да, чыгымнарны куып җитә торган түгел. Бер сыер тотуны аклар өчен сөтнең литры ким дигәндә 100 сумнан сатылырга тиеш, – дип саный тәҗрибәле фермер.

Сыер асраучылар да, шуны аңлап, ягъни файдасы күбрәк булсын дип, сөтне сатып алучыга үз юллары белән илтеп җиткерү ягын кайгырта. Ягъни чиста, сыйфатлы чимал җитештерүче намуслы хуҗалар сөтләрен базарга я үзләре илтеп сата, яки махсус кешеләргә биреп җибәрә.

– Без аларны «күләгәдә сату итүчеләр» дибез, – ди эшмәкәр Миңзөфәр Исмәгыйлев. – Бер авылда яшәүче биш-алты кешедән сөт җыеп алалар да, аларны эшкәртеп, яки шул килеш кенә базарга илтеп саталар. Билгеле, бәяне дә югары куялар. Безгә исә калган кешеләр тапшыра. Бу безнең ише фермерларга бер дә яхшыга түгел. Икенчедән, дөреслек тә юк. Без лаборатория анализлары өчен ай саен үз кесәбездән билгеле бер хак чыгарып салырга мәҗбүр булсак, базарга илтеп сатучылар бер тиен дә түләми.

Арча районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе урынбасары Ленар Абдуллин әйтүенчә, районда халыктан җыела торган сөткә уртача бәя 29 сумны тәшкил итә. Бу, узган ел белән чагыштырганда, 7 сум 50 тиенгә күбрәк дигән сүз.

– Корылык булып, ашлыкка кытлык килгәч, бәяләр шактый артты. Ләкин алай да бу бәяне канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый әле, – дип саный җитәкче.

Районда халыктан җыеп алынган сөткә 30 сум 50 тиен түләүчеләр дә, 27 сум 50 тиен бирүчеләр дә бар. Апаз, Үрнәк авыл җирлекләрендә югарырак бәя куелса, Яңа Кырлай авыл җирлегендә 27 сум 50 тиен түлиләр.

– Апаз, Үрнәк авыл җирлекләре Балтач зонасына якын, шуңа күрә анда көндәшлек зур. Бәяләрдәге аерманың сәбәбе әнә шунда. Дөрес, эре хуҗалыкларда бәяләр аерыла. Анда, билгеле, сөтнең сыйфаты да башка. Алар заводларга сөтнең литрын 32–33 сумга тапшыра, – диде Ленар Абдуллин.

Башка районнар савым сыерлары саны кими дисә, Арчада күрсәткечләр үзгәрешсез калган.

– Узган ел белән чагыштырганда, шәхси хуҗалыклардан сөт 2 тоннага артыграк җыела. Көн саен 38 тонна тирәсе чыга. Узган ел ахырындагы мәгълүматлар буенча, райондагы шәхси хуҗалыкларда 6097 баш сыер исәпләнә иде, быел әлегә төгәл мәгълүматлар юк, ләкин күрсәткечләр шул тирәдә дип чамалыйбыз, – диде идарә җитәкчесе.

Сөт җыючылар шулай ук Азнакай районының Урманай авылы халкын да кыерсытмыйлар икән. Анда литрына 28 сумнан түлиләр. Авылда ике кеше сөт җыя. Берсе – үз авыллары егете, икенчесе – Мөслим районы кешесе. Икесе дә бер үк хак түли.

– Шушы көннәрдә декабрь ае өчен түләү алдык. Литрына 28 сум биргән, – диде Гөлнур Камаева. – Бик яхшы инде бу бәя. Аннан алдагы айда 27 сумнан түләгән иде. Ай саен бәя үсүгә таба баргач та күңел була. Җәен дә, күрше-тирә авыллар белән чагыштырганда, иң зур хакны безнең сөт җыючы куя. Ләкин ашлык бәясе белән чагыштырганда, барыбер арзан инде. Быел бер кило арпаны 18 сумнан сатып алдык бит.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Башта – фатир, аннан – акча

Узган елның 1 декабрь мәгълүматлары буенча, республикада 15 меңгә якын гаилә торакны өлешче буларак төзетә. Аларның банклардагы махсус счетларында (эскроу-счет дип атала) 57,9 миллиард сум акча ята. Төзелеш төгәлләнгәч кенә, акча төзүче оешмаларга тапшырылачак. «Башта – фатир, аннан – акча» дигәнне күздә тоткан шушы тәртип кертелгәннән бирле 10,8 мең чамасы фатир файдалануга тапшырылган инде. Өлешчеләргә шушы нигездә торак төзү күрсәткечләре арта. Узган ел башыннан бирле эскроу-счетлар саны – 2,2 тапкыр, аллардагы акча күләме 76,8 процентка арткан.

Инде әйткәнебезчә, төзүчеләр йортны файдалануга тапшырганнан соң гына сатып алучыларның акчасын ала. Шул рәвешле намуссыз компанияләрнең өлешчеләрне алдавына чик куела. Россия Үзәк банкының Татарстандагы бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин әйтүенчә, 2021 елның 11 аенда якынча 39,3 миллиард сумга торак төзелеп, сатып алучыларга тапшырылган.

Бердәнбер өметле шәһәр

Узган елда Казан Идел буе федераль округында, халкы миллионнан арткан шәһәрләр арасында туучылар саны үлүчеләр санынан арткан бердәнбер шәһәр булган. Татарстан башкаласы коронавирус пандемиясе чорында инде менә икенче тапкыр шундый нәтиҗәгә ирешкән. Былтыр Казанда 20501 бала дөньяга аваз салган, 18535 кеше үлгән. Шул ук вакытта 2021 елда шәһәрдә үлем-китем күрсәткече алдагы елдагыга караганда 10 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, нарасыйларның 41 проценты – гаиләдә беренче бала, 40 проценты – икенче, 19 проценты – өченче һәм шуннан соңгы бала булып дөньяга килгән. 280 гаиләдә – игезәкләр, ике гаиләдә берьюлы 3 игезәк бала туган. Исемнәргә килгәндә, кызлар арасында иң киң таралган исем – Әминә (294 сабый), малайлар арасында – Әмир (317).

COVID-19

Читкә карап, гыйбрәт аласымы?

Бар караш чит илләргә төбәлгән. Европа һәм АКШ илләрендә коронавирус инфекциясе белән чирләүчеләрнең 70–75 процентында «омикрон» штаммы ачыклана. Белгечләр аның «дельта»га караганда да тизрәк таралуын, шул ук вакытта бик аз очракта гына авыр формада узуын әйтә. Чит илләрдә вакцина ясатучыларның саны бермә-бер күбрәк булуын исәпкә алу да кирәктер. Прививка ясатмаучылар чирне ничек кичерер дә «омикрон» Россиядә үзен ничек күрсәтер?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның «шимбә киңәшмәсе»ндә дә, әлбәттә, бу хакта сүз булды. Республика җитәкчесе теләсә нинди үзгәрешкә әзерлек булырга тиеш дип кисәтте.

– Обсерваторлар әзер торсын. Хастаханәләрдә исә дарулар һәм башка кирәк-яраклар булырга тиеш, – диде Президент. Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта хастаханәләрнең коронавируслы сырхаулар өчен билгеләнгән 2570 урынның 1638ендә авырулар ята.

– Чикләү чараларының барысы да гамәлдә калачак. Әлегә ниндидер үзгәрешләр кертергә мөмкинлек тә юк, моның өчен нигез дә күрмибез, – диде бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов. Президент искәрткәнчә, республикада 400 меңләп вакцина бар, прививка ясату өчен 170 урын билгеләнгән, аларның кайберләре тәүлек буе эшли.

Билгесезлек белән очрашу куркыта, әлбәттә. Инфекциянең яңа штаммыннан да, бәлки, күпләр үзгә билгеләр көткәндер. Әмма белгечләр «омикрон» башка «туган»нарыннан әллә ни аерылмый, ди. «Аермалары аз. Ул да булса – баш авырту, борын тыгылу, хәлсезлек, төчкерү. Сырхаулар үзләре дә, белгечләр дә «омикрон» йоктырган кешеләрдә менә-менә авырып китү хисе барлыкка килүен әйтә», – дигән иде Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына таянып, Чаллы пульмонологы Лариса Танова үзенең «Инстаграм» сәхифәсендә «омикрон»ны ничек аерырга икәнен өйрәтә.

– Коронавирустан прививка ясату чирне җиңел кичерергә ярдәм итәчәк. Сирәк очракта үпкәләргә зыян килергә мөмкин, – дип хәбәр итә табибә. – Шулай да, алдан фаразлау кыен. Чирнең катлаулы очраклары да булмый калмас. Хроник авырулары булган кешеләргә, гомумән, барыбызга да үз иммунитетын кайгыртыр вакыт. Ферритин, кандагы шикәр, С-реактив аксым күләмен тикшерергә киңәш итәм. Ашау-эчүгә игътибар итәргә, баллы, ак оннан әзерләнгән ризыклардан баш тартырга, күбрәк яшелчә, яшел тәмләткечләр ашарга кирәк. Борын эченә составына эфир майлары кергән кремнар сылау да файдалы булыр. Әле вакцина ясатырга өлгермәгәнсез икән, ясатырга кирәк.

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Дмитрий ЛОПУШОВ, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы:

Әгәр без туганнарыбызны һәм якыннарыбызны югалтырга әзер икән, барысына да төкерергә – битлек кимәскә, вакцина ясатмаска, кулыбызны антисептик белән сөртмәскә мөмкин. Тик андыйлар акылы булган кешеләр сафына керәме? Миңа калса, җавабы билгеле.

КАЗАН АЭРОПОРТЫ – САННАРДА

Г.Тукай исемендәге «Казан» халыкара аэропортында узган ел 3 млн 876 мең юлчыга хезмәт күрсәтелгән. Бу – пандемиягә кадәрле 2019 елгы күрсәткечтән 11,7 процентка күбрәк.



ИЛ ЭЧЕНДӘ ОЧЫШЛАР
43 юнәлеш
2 млн 835 мең юлчы

ХАЛЫКАРА ОЧЫШЛАР
30 юнәлеш
1 млн 41 мең юлчы

Туристлар Татарстанны сайлый

Татарстанда узган елда 3 миллион турист булып киткән. Бигрәк тә Мәскәүдән, Санкт-Петербург, Самара, Уфа, Чабаксар, Екатеринбург һәм Түбән Новгородтан килүчеләр күп. Гомумән, 2021 елда туристлар саны пандемиягә кадәр чордагыга – 2018 ел күрсәткеченә (3,2 миллион сәяхәтче) якынлашкан. Ә менә 2020 елда пандемия сәбәпле Казанга нибары 1,7 миллион турист килгән. Сәяхәтчеләр бигрәк тә Кремльгә, Бауман урамы, Иске Татар бистәсе, Кремль яр буена, «Казан Ривьерасы» аквапаркына һәм төрле музейларга мөкиббән. Аларны шулай ук яңа ачылган урыннар: Мәрьям ананың Казан иконасы соборы, «Урам» экстрим-паркы, «Союзмультпарк» мультимедиа үзәге җәлеп иткән.

Сүз уңаеннан, Яңа ел бәйрәмнәрендә республика 140 мең туристны кабул иткән. 2–9 гыйнвар чорында кунакханәләр 90 процентка тулган.

Җылыта

Бу атнада Татарстанда җылы булачак. Якындагы көннәрдә һава температурасы –8 градустан төшмәячәк. Бу хакта Татарстан Гидрометеоүзәге хәбәр итә. Синоптиклар әйтүенчә, сишәмбе – 19 гыйнварда Татарстанда кар-буран көтелә. Көндез –1…–6, төнлә –3…–8 градус, секундына 17 метрга кадәр тизлектә көчле җил. Пәнҗешәмбе – 20 гыйнварда республикада урыны белән кар явып үтәчәк. Көндез –3…–8, төнлә –6…–11 градус. Җомга һәм ял көннәрендә дә кар-буран, көчле җил көтелә. Көндез һава температурасы –6…–11, төнлә –9…–14, урыны белән 19 градус салкын булачак.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАРРЕЛЬ КАЯ БАРА?

Үткән атнада дөнья сәясәтендә һәм икътисадында «һава торышы»н «омикрон» һәм Украина тирәсендәге киеренкелек билгеләде. Коронавирусның яңа штаммы авыру йоктыручылар саны буенча янә рекордлар бирә. АКШта бер көнгә 3 миллион яңа авыручы теркәлүе хакында да хәбәрләр ишетелә.

Бу мәсьәләдә без гадәттә Израильгә карыйбыз, чөнки ул, бердән, халык саны ягыннан Татарстаннан ике ярым тапкыр гына зуррак, икенчедән, вакциналаштыру буенча лидерларның берсе. Хәтерлик әле: көзге дулкында Татарстанда бер көнгә чир йоктыручылар саны ике йөздән арткач, без чаң кактык һәм кырыс чикләүләр режимында яшәүгә күчтек. Израиль корона-кабинеты консультанты профессор Эран Сегаль дүшәмбе иртәсендә якындагы көннәрдә Израильдә COVID-19ның 40–50 мең (!!!) яңа очрагы ачыкланачагын, әмма бу – айсбергның күренгән өлеше генә, чынлыкта авырулар саны 3 тапкыр күбрәк булачагын игълан итте. Израиль өчен 50 мең – коточкыч зур сан, әмма бер нәрсә өметләндерә: болар – җиңелчә авыручылар. Авыр хәлдәгеләр саны 650–850 булыр дип көтелә. Атна ахырында андыйлар 386 кеше булган. Каты авыручылар санын Татарстан масштабына күчерсәк, хастаханәләр өчен зур киеренкелек тудыручы вазгыятьне шәйли алырбыз. Шуңа күрә профилактикага зур игътибар бирү таләп ителә.

Менә шундый авыру таралу һәм хәрби киеренкелек тудырган фонда нефтькә бәяләр үсә. «Кара алтын» базарлары буенча чит ил белгече, фаразлары күпчелек очракта дөреслеккә туры килә торган аналитик Даг Кинг, нефть чыгару тармагына инвестицияләр җитәрлек булмау сәбәпле, базарның структур инфляция кичерәчәген әйтә. Аның фаразы мондый: якын арада баррель 100 долларга җитәчәк, якындагы биш елда аның бәясе 200 долларга кадәр үсәргә мөмкин. Чимал инфляциясе 1970 нче еллардан соң иң зурысы булыр, ди белгеч. ОПЕК+ илләре ай саен квотаны 400 мең баррельгә арттырырга килешсәләр, декабрь аенда нефть чыгару 250 мең баррельгә генә үскән. «Кара алтын»ны иң күп чыгаручы Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кувейтның гына өстәмә баррельләр чыгарырга куәтләре җитәрлек. Кинг фикеренчә, Россия инде үзенең югары ноктасында тора һәм базарга өстәмә нефть чыгарырлык хәлдә түгел.

ОПЕКта һәм Халыкара энергетика агентлыгында Кингның фикере белән килешмиләр. Бу ике оешма базарда «кара алтын» җитәрлек, хәтта артык та әле дип саныйлар. ОПЕКка кермәгән илләр: Бразилия, Канада, АКШ тырышлыгы белән 2022 елда «кара алтын» чыгару бер көнгә 6,4 миллион баррельгә артачак, ди алар.

Хәзерге вакытта без чимал бәяләрен фаразлау мөмкин түгел дип саныйбыз, чөнки көтелмәгән хәлләр төрәне вазгыятькә тирән эз салып бара. Россия нефть экспортлаучы ил булса да, бәяләрнең рекордлы үсеше аңа һичбер файда бирмәячәк, чөнки ул кәгазь валюталарның очсызлануын гына аңлата. Бензинга һәм башка товарларга бәя үсеше рәвешендә ул барыбызның да кесәләрен генә чистартачак.

Россиядә

АКЦИЯЛӘР ТӨШӘ, ДОЛЛАР МЕНӘ

Россиядәге үткән атнадагы эчке вазгыятьне без язманың баш исеме белән бәяли алабыз. Россия югары җитәкчелегенең – АКШ, дипломатларның НАТО блогы белән сөйләшүләре уңышсыз тәгәлләнде. Ике як та үзләренең принципларына ябышып яттылар, компромисска барырга теләмәделәр. Россия дипломатиясе бу уңайдан кискен белдерүләр ясады. Башта тышкы эшләр министры урынбасары Рябков әфәнде Женевада кискен игълан белән чыкты, аннан соң министр Лавров: «Без озак җиктек, хәзер кузгалырга вакыт», – дигән рус әйтемен кулланып, инвесторларның котын алды.

Лавровның белдерүе Вашингтонда Россиянең югары җитәкчелегенә персональ санкцияләр кертергә әзерләнүләре белән бәйле иде. Дөрес, санкцияләр Россия Украинага каршы сугыш башлаган очракта гына вәгъдә ителә. Мәскәү сугышырга җыенмавын һәрдаим ассызыклап тора, әмма Көнбатыш күрше илдә һөҗүм итү кораллары урнаштыра башласа, кискен җавап бирәчәген дә яшерми. Менә бу «кискен җавап»ны инвесторлар үзләренчә аңлыйлар инде һәм базарлар җимерелә. Сүз Россиядәге фонд базарларының түнтәрелеше турында бара. Мәскәүдәге ике төп биржа: ММВБ да, РТС та үткән атнаның икенче яртысында кискен тетрәнү кичерделәр, кыйммәтле кәгазьләрнең бәясе түбәнгә атылды. Кыска гына вакыт эчендә 3 триллион сумлык куык тишелеп, акча җилгә очты. Шундый мизгелләр булды: Норникельнең югалтулары – 4,2 миллиард, Роснефтьнеке – 5,5 миллиард, Газпромныкы – 7,8 миллиард, Саклык банкыныкы 10 миллиард долларга җитте. Ике көн эчендә Россиянең фонд базары 40 миллиард доллардан артык акча югалтты, диделәр. Дәүләт облигацияләре дә тишеккә очты. Доллар үзенең югары ноктасында 77 сумга кадәр бәяләнә башлады.

Шуннан соң кызык хәл туды: Мәскәү санкцияләрдән курыкмавы турында кычкырып торганда, аларның куркынычы турында чит ил сәясәтчеләре, аеруча европалылар шаулый башлады. Базарларны тынычландыру өчен, фин җитәкчелеге үзенең НАТОга керергә җыенмавын игълан итте. Россия дипломатиясе финнарның Көнбатыш блокка кушылуларын «кызыл сызык»ларның берсе дип санавын белдергән иде. Германиянең зур сәясәтчеләренең берсе Фридрих Мерц Россиянең банкара SWIFT системасыннан өзелүе дөнья базарлары өчен «атом бомбасы»на тиң булачагын әйтте. Бу, чынлап та, шулай.

Европа сәясәтчеләренең борчылуы аңлашыла, чөнки Көнбатыш спекулянтлары Россиянең кыйммәтле кәгазьләрендә байтак акча тоталар. Бер Россия финанслары гына түгел, халыкара спекулянтлар да зур югалтулар кичерә. Европалыларның конфликтны сылап-сыйпап йомшартырга тырышулары фонд базарын аз гына тынычландырды, әмма биржа сәүдәсе барыбер минус белән тәгәлләнде. Сумның курсы гына бераз ныгыды. Бу атнада да түбәнәю дәвам итсә, ул безнең, биржа сәүдәсендә катнашмаучы күпчелекнең, кесәсендә дә бәяләрнең яңа күтәрелүе рәвешендә кайтаваз бирәчәк.

БӘЯ БЕЛӘН СЫЙФАТ ТА ҮССЕН



Илдар Мөхәммәтҗанов

Июль башында кайбер коммуналь хезмәтләр өчен бәя артачак. Бу хакта Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Александр Груничев еллык киңәйтелгән утырышта хәбәр итте.

Татарстан буенча эчәргә яраклы суның бәясе – 4,7, аккан суларны чыгару бәясе 9,2 процентка артачак. Суның бер кубометрының уртача бәясе – 28 сум 69 тиен, бер кубометр су чыгарган өчен 26 сум 2 тиен түлисе булачак.

Җитәкче сүзләренчә, 1 июльдән көнкүреш калдыкларын чыгару өчен дә 4 процентка артыграк түләячәкбез. Утка да, газга да, җылылык энергиясенә дә бәя артачак. Газга бәя узган елның 1 гыйнварыннан арткан иде – ул 6 сум 7 тиен булды. Июль башыннан исә тагын 3 процентка арту көтелә. Газ плитәсенә килгән ягулык өчен шәһәрдә җәен 4 сум 30 тиен түли башлыйбыз, авыл җирендә аның бер кубометры 3 сум да 1 тиенгә төшәчәк. Электр энергиясенә бәяләр 4,6 процентка артачак.

Комитет җитәкчесе аңлатуынча, тарифларны арттыруның төп сәбәпләре – халыкка хезмәт күрсәтүне яхшырту, күп кенә җитешсезлекләрне бетерү, үсеш программаларын арттыру. Суга бәя артуның сәбәпләрен исә «Водоканал» оешмасының генераль директоры Андрей Егоров инженер челтәрләренең искерүенә бәйле дип аңлатты. Аларны яңарту таләп ителә. Күбесе 1950 нче елларда төзелгән, 70 проценттан артыгына ремонт кирәк. Соңгы биш елда су торбаларына бәйле 616 авария булган. Хәзерге вакытта республиканың 2 мең күпфатирлы йортны һәм 20 мең шәхси йортны су белән тәэмин итүче җиһазлар төзекләндерү көтә.

Бәя арту белән сыйфат та яхшырыр дигән өмет бар. «Сетевая компания» оешмасының генераль директоры Илшат Фәрдиев сүзләренә караганда, электр челтәрләре күптәннән заманча технологияләр буенча хезмәт күрсәтә.

– Элек авария булган урынны табар өчен 2–3 сәгать кирәк булса, хәзер без ул урынны 57 секунд эчендә табабыз. 2014 елда электр челтәрләренең кулланышын тәэмин итү өчен юл картасы ясадык. Хәзер шул карта ярдәмгә килә. 4 ел эчендә 270 мең интеллектуаль исәпләгеч куелды. Ул энергия куллануны 5,4 процентка киметте. Шул рәвешле югалтулар да азайды, – диде ул.

Утырышта катнашкан Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин, тарифларны көйләү системасы һәрдаим үзгәреп тора, дип искәртте. Фикер алышуларга халыкны активрак җәлеп итәргә кирәклеген әйтте.

– Дәүләт комитетына тариф карарларын, инвестиция программаларын кабул итү, шулай ук коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне арттыруны булдырмау буенча ачыктан-ачык фикер алышуны дәвам иттерергә кирәк, – диде Премьер-министр. Шул ук вакытта тарифларны исәп-хисап ысуллары белән генә түгел, ә министрлыкларда булган объектив мәгълүматлар буенча формалаштыру мөһим. Хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру өстенлекле бурыч булып тора. Шул ук вакытта җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттырып, чыгымнарны киметеп, өзлексез һәм сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә ирешергә кирәк.

Алексей Песошин кайбер район җитәкчеләренә дә мөрәҗәгать итте. Баксаң, районнарда ресурс белән (җылылык, су, газ, электр) тәэмин итүче оешмаларга күчеп бетмәгән милекчеләр бар икән. Бу эшне дә тизләтергә кушты. Шулай ук транспорт хезмәте күрсәтүчеләр арасында да эшен җиренә җиткереп башкармаучылар җитәрлек. Шундыйлар аркасында халыкка хезмәт күрсәтү сыйфаты кими. Алексей Песошин бу өлкәдә дә тарифлар буенча барлыкка килгән сорауларның чишелешен табарга киңәш итте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Нәтиҗә

Янгын гына булмасын!

2021 елда эссе һава торышы сакланып, янгын чыгу куркынчы зур булганга, урманнарда биш тапкыр чикләүләр кертелде. Соңгы 5 ел эчендә янгын куркынычы янаган чорның уртача озынлыгы 185 көн тәшкил итә, узган елны ул 193 көн дәвам иткән. Бу хакта Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров киңәйтелгән еллык утырышта сөйләде.

– 2021 елда республиканың урман фонды территориясендә 210 гектар мәйданда 19 урман янгыны теркәлде. Шулай ук аеруча саклана торган табигый мәйданнарда 7 янгын булды. Әмма шуңа да карамастан, урман янгыннарының таралу куркынычын киметә алдык, – ди Равил Кузюров. – «Экология» илкүләм проектының «Урманнарны саклау» федераль проекты ярдәмендә кимегән һәм торгызылган урманнар нисбәтен 100 процентка җиткердек. Әлбәттә, әлегә урман мәйданнары белән мактанып булмый. Алар бары тик 17,5 процентны (республика мәйданының. – **Ред.**) тәшкил итә. Әмма бу юнәлештә күп эшләр башкарылды.

Министр орлык әзерләү, кәлшәләр үстерү турында да сөйләде. Ел дәвамында республика урманчылыкларында 40,2 тонна орлык әзерләнгән. 34,1 миллион данә утыртыр өчен үсенте, Саба селекция-орлыкчылык үзәгендә 12 миллион данә ябык тамырлы кәлшәләр үстерелгән.

– Язын «Хәтер бакчасы» дигән халыкара акция кысасында 1,1 миллион данә агач утыртылды. Бу чара Бөек Ватан сугышында ятып калган якташларыбызны искә алып уздырылды. Көзен «Урманнарны саклыйк» дигән бөтенроссия акциясендә катнашып, 594 гектар мәйданда 1,8 миллион данә агач утыртылды. Чистарту өмәләрендә катнашабыз. Урманнарны чиста тоту өчен күп кенә чаралар уздырылды. Узган ел Татарстан урманнарыннан 2 мең кубометр каты көнкүреш калдыгы чыгарылды, – дип сөйләде министр.

Өмәләр оештыру, агач утырту белән беррәттән үсентеләрнең исәбен алу, аларны төрле авырулардан саклау янәшәсендә цифрлаштыру эше дә дәвам итә. Узган ел Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең берникадәр өлеше электрон рәвешкә күчерелгән. Быел бу эшне дәвам итмәкчеләр. 2022 елда Урман хуҗалыгы министрлыгы «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша электрон хезмәт күрсәтүне 80 процентка җиткермәкче була.

Министр урманнарны саклауга да тукталды. Агач утыртып, корыганын яңага алыштыру гына түгел, урманга килгән зыян хакында да сөйләде. Бер ел эчендә урман инспекторлары 20 мең тапкыр тикшерү үткәргән. Алар урманга зыян салучыларга 402 беркетмә төзегән. Урманга 56 миллион сумлык зыян килүе ачыкланган.

Равил Кузюров халыкның урманнарга карата игътибарлы булуын сорады. Янгыннарның да үзеннән-үзе килеп чыкмавын әйтте. Премьер-министр урынбасары Камил Нигъмәтуллин да үз чыгышында узган елгы урман янгыннары темасын читләтеп узмады.

– Шырпы, тәмәке төпчеге ташлау гына түгел, кояш астында яткан пыяла да ут чыгуга сәбәпче була ала. Шуңа да урманнарны саклау буенча халыкка аңлату эшләре алып барырга кирәк, – диде ул. – Быел Цифрлаштыру елы икәнен онытмыйк. Урман хуҗалыгындагы документларны электронлаштыруны дәвам иттерергә кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯЗДАН КӨЗГӘ КАДӘР ЭШЛИСЕҢ ДӘ...

Авыл капкасы

Авыл кышын йоклыймы? Бер елны шушы сорауны биргәч, районның ул чактагы бер хуҗалык җитәкчесе җиңелчә генә шелтәләп тә алган иде: «Инде син дә шәһәрләштең мәллә?!» Янәсе, нинди тузга язмаган сорау бу!

Бер яктан, ул хаклы: хуҗалык җитәкчеләре бит: «Кыш буе киләсе ел өчен эшлибез», – ди. Безнең Балтач районында, мәсәлән, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче җитәкчеләр, баш белгечләр елның беренче семинар-очрашуын язгы кыр эшләренә әзерлеккә багышлый. Гадәттә ул елның беренче көннәрендә уза да. Көзге эшләр бетүгә үк инде авыл хуҗалыгы техникаларын ремонтлау башлана, яңа елга кадәр тәгәлләүчеләр дә бар, ашлама туплыйлар, агу-химикатларга, яңа төр сортларга, техникаларга, тагылма машиналарга һәм башкасына заказлар-заявкалар бирәләр, иркенрәк чорда басуларның картотекасын яңарталар, кайсы басуга нәрсә чәчәргә планлаштыралар. Кемнәрдер тирес чыгара, кемнәрдер көзен басуларда калган эскертләрне ферма яннарына, кардаларга тарттыра... Болар барысы да иртә яздан караңгы көзгә кадәр эшләр яхшы барсын өчен эшләнә.

Дөрес, авылда яшәүче күпләр: «Җәй буе эшләгәннең әҗерен күрәбез, рәхәтләнеп йоклыйбыз. Ни дисәң дә, ул чор белән чагыштырганда, эшләр күпкә азрак, җиңелрәк», – ди анысы. Дөресе шулай, фермага сменага эшкә баручыларны исәпкә алмаганда, иртәнге дүрттә әле авыл өйләрендә тәрәзәләрдә ут күренми, кичен дә гадәттәгедән иртәрәк ятабыз... Быелга кадәр бездә дә шулай иде. Башка елларны бу вакытта сыер сөт ташлый да, мин үзем бөтенләй коммунизмга күчә идем. Иртән абзарга чыгып та торасы юк. Быел сыерның буазлык срогы үзгәрде. Өстәвенә башка елларда кышкы чорда шәхси хуҗалыклардан сөтне соңрак һәм ике көнгә бер генә җыялар иде. Быел сөт җыючыларга тагын бер авылны өстәделәр дә, хәзер сөтне көндәлек һәм иртә җыялар. Сәгать бишләрдә инде алар күрше Биктәш авылында сөт җыйнап, безнең авылга килеп җитә. Дөрес, бер сыерлы буларак, безгә ташлама ясадылар: ике көнгә бер генә тапшырабыз. Күп сыер асраучыларны исә кисәтеп торалар: сөтегезне көндәлек тапшырыгыз, алайса, цистерналарда урын җитми.

Сөткә бәяләр тотрыклы торганның файдасы: бездә сыер асраучылар кимемәде. Җәй шактый коры килеп, терлек азыгы әзерләп булмас инде, ашлыгы-фуражы да бик кыйммәт, диешсәк тә, шөкер, сыер санын киметүче булмады дип беләм. Авыл кешесе инде эшне аны болай да авырсынмый эшли. Тияре генә булсын. Иткә-сөткә бәяләр генә тотрыклы торсын. Әле декабрь аена исәп-хисап ясалмады, ноябрьдә саткан бер литр сөт өчен 29 сум тирәсе түләнде. Безнең өчен моңа кадәр күрелмәгән сан. Әмма бу көннәрдә социаль челтәрләрдә Казандагы бер кибеттә «Татарстан продукты» дип язылган этикеткада бер литр сөтнең бәясе 72,99 сум булуын шаккатып куйганнар иде. Без, авылныкылар, аптырамыйбыз инде, без бит чиләкләп, гади авыл сөте генә сатабыз. Матур шешәгә дә тутырылмаган, «шәп сыер сөте» дигән рекламасы да юк... Шәһәрнекеләрдә ялгыш фикер тумасын, авылныкылар шул бәягә сөт сатып, балда-майда йөзә дип көнләшмәсеннәр дип кенә яздым.

Хәер, төп сүзебез кышкы йокы турында иде бит. Каланыкылар белән чагыштырганда авыл халкының күп булып тоелган кышкы йокысы да ташка үлчим генә булып калачак анысы. Кар көрәргә көрәге дә булмаган, шул сәбәпле, машинамны кар күмеп китте, йөреп булмый дип зарланучы каланыкылардан аермалы буларак, авыл кешесе кыш салкын, бозлы-карлы булырга тиеш дип кабул итә, карын да көри, бозын да вата, салкынына да сабыр итә... Әле шәһәрнекеләрдән аермалы буларак, эштән кайтып, якты, җылы фатирларга кереп утыру белән генә аның өчен кыш «тәмамланмый», абзар тулы терлеге, кош-корты өчен үзеннән дә бигрәк хафалана авыл агае.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл җирлекләренә дә бу чорда федераль трассага кермәгән авыл урамнарын, тыкрыкларны чистартуны оештырырга кирәк. Бу – шактый җитди проблема. Шөкер, ул яктан без бәхетле. Кечкенә авыл булсак та, юлыбызның бер өлешен күп еллар инде юллар идарәсе карап-тәртипләп чистартып тора. Буранлы төннәрдә хәтта төнен дә берничә әйләнәләр, иртән иртүк без йокыдан торганчы юлларны чистартып өлгерәләр. Элек гел кар күмә торган урыннар бу, шуңа күрә кышын юлсызлыктан тилмерүнең ни икәнен онытмаган өлкәннәр бигрәк тә сөенә бу хәлгә. Авылның түбәнге өлешен исә хуҗалык техникасы чистарта, шәхси тракторлар да тыкрыкларны, капка төпләрен чистартып бирә.

Килешәсездер, эше-мәшәкате, проблемасы булса да, кыш кары белән матур. Бу көннәрдә сихри кары, саф һавасы белән кинәндерде табигать. Шушы матурлыкны күрергә, эссе җәйләрдә сагындырган кышларда хозурланып калырга иде. Ә бит әле генә кышка кергән кебек идек. Баксаң, инде аның да яртысына җиткәнбез. Кышкы йокыларны сагыныр чаклар да ерак түгел, димәк.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ИНДУС ТАҺИРОВ:

«ШӘЙМИЕВ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЯЗМЫШЫН ИЛ ЯЗМЫШЫ БЕЛӘН БӘЙЛӘП ЭШ ИТТЕ»

Беренче Президент

Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тарих битләренә Россияне федератив рельсларга бастыручыларның берсе буларак кереп калды. Юбилейга кагылышлы форсаттан файдаланып, әлеге вакыйгаларның үзәгендә кайнаган академик Индус ТАҺИРОВ белән тагын бер кат фикерләрне яңартып алырга уйладык.

– Минтимер Шәриповичны ихластан 85 еллык юбилее белән котлыйм. Изге эшләрен һаман шулай уңышлы рәвештә дәвам иттерә күрсен иде дигән теләктә калам. Әйтергә кирәк, Беренче Президентыбыз турында бик күп язылды. Аның илебез, татар тарихына керткән өлешен төрле яклап бәяләгән берничә китап дөнья күрде, төрле телләрдә басылган мәкаләләр санап бетергесез. Һичшиксез, аның турында әле күп язылачак. Шуңа күрә күз алдыннан үткән кайбер гамәлләрен генә әйтеп китәсем килә. Безнең хәтеребездә ул СССРның таркалып юкка чыккан җаваплы көннәрендә киләчәкне ныклап күзаллый торган стратег буларак саклана. Минтимер Шәймиев, Россияне демократик нигездә үзгәртеп, федератив рельсларга бастырып, илне саклап калу мөмкинлегенә инанган шәхесләрнең берсе булды.

:: Индус Ризакович, хәтерләрне яңартып алу максатыннан, туксанынчы ел вакыйгаларына тукталып үтик әле...

– 1990 нчы еллар татарларга республиканың үзбилгеләнү хокукын көйләүгә юл ачты. Мин монда беренче урында 1990 елның 30 августында кабул ителгән Декларацияне күрсәтер идем. Әлеге документта, союздаш республика хокукларын алып, мөстәкыйль рәвештә имзалану бурыч итеп куелды. Бу – Россия белән тигез хокуклы булып, бергә яшәү дигән сүз иде. Моны махсус позиция дип атадылар. Бик озак сөйләшүләрдән соң, ниһаять, Декларацияне таныта алдык. Тик, ни кызганыч, соңгы сөйләшүләр 16 августта булып, 19 августта ГКЧП башланды. Шулай итеп, безнең документка кул куярга мөмкинлек бикләнде.

:: Шул ук вакытта СССР таркалды. Ул гына да түгел, Россиянең бөтенлегенә куркыныч яный башлады. Килеп туган бу вазгыятьтә Беренче Президентыбызның роле нинди булды?

– Бу чор Татарстан тарихында бик катлаулы буларак истә калды. ГКЧПны яклаган өчен дип, Минтимер Шәймиевкә хәтта җинаять эше ачылды. Әмма без максатыбызның кемне дә булса яклау түгел, ә республикадагы тотрыклылыкны саклап калу икәнлеген аңлата алдык. Җитәкчеләребезгә карата ачылган җинаять эшләре туктатылды. Ничек кенә булмасын, Россиянең таркалуын булдырмый калуда Минтимер Шәриповичның роле гаять зур. Моның шулай икәнлеген Россиянең ул вакыттагы Президенты Борис Ельцин, хөкүмәт башлыгы Виктор Черномырдин да танырга мәҗбүр булдылар. Россиянең бүгенге Президенты Владимир Путин Шәймиевне юл күрсәтүче пионер дип бәяләде. Бу чыннан да шулай. Чечнядагы канлы вакыйгалар, кайбер башка төбәкләрдәге сепаратизм хәрәкәтләре Россия бөтенлегенә янаучы әзер җирлек иде инде. Нәкъ шул вакытта Татарстан, суверенлык Декларациясе кабул итеп, ике яклы килешү төзеп, Россиянең исән-имин калуына саллы өлеш кертте.

:: Димәк, Татарстаннан үрнәк алып, тормышларын җайга салырга теләүчеләр күп булды дип әйтергә дә урын бар?

– Татарстан артыннан Россиянең 40ка якын субъекты Үзәк белән вәкаләтләр турында килешүләр төзеделәр. Әмма Татарстанныкы кебек документ беркемдә дә булмады. Аның эчтәлеге бөтенләй башка. Әйткәнемчә, ул, союздаш республика хокукларын алып, мөстәкыйль яшәүне күздә тота иде. Безнең килешү шулай ук халыкара мөнәсәбәтләрне хәл итү өчен дә үрнәк булды. Сербия, аның составындагы бәйсезлеккә омтылган Косово турындагы сөйләшүләр вакытында чарада катнашучыларның өстәлләренә безнең килешү таратылган иде. Ул Косовоның суверенлыгын Сербиянең бөтенлеге белән тәңгәлләштерү үрнәге рәвешендә тәкъдим ителгән. Шулай ук бу үрнәк мөстәкыйльлек юлына баскан Көньяк Осетия белән Абхазияне үз составында калдыру максаты белән Грузиягә дә тәкъдим ителгән иде. Ләкин, ни кызганыч, Грузия җитәкчелеге проблеманы мондый юл белән түгел, ә көч белән хәл итмәкче булды. Барып чыкмады. Нәтиҗәдә әлеге республикалар бәйсезлек игълан иттеләр. Грузия өчен бу зур югалту иде.

:: Татарстандагы милләтара мөнәсәбәтләр, диннәр дуслыгы Җир шарындагы күпмилләтле илләр өчен үрнәк булып тора. Минтимер Шәймиевне дөнья авыр проблемаларны уңышлы хәл итә белүче буларак кабул итә.

– Килешәм, әмма Минтимер Шәриповичның Татарстан, татар халкының язмышын беренче урынга куеп эш иткәнлеген билгеләп үтмәсәм, дөрес булмас иде. Әйе, ул республикабызның, халкыбызның язмышын ил язмышы белән бәйләп эш итте. Бу сүзләргә мин махсус рәвештә басым ясыйм. Чөнки кайберәүләр аны Россияне таркатырга, Татарстанны Россиядән чыгарырга тырышучы итеп күрсәтергә омтылды. Ләкин тарих моның чеп-чи ялган икәнлеген үзе раслады. Дөреслектә исә илнең иң җаваплы борылыш елларында Шәймиев Россиянең бөтенлеген яклаучы булды.

Татарлар – сибелеп яши торган халык. Аларның күпчелеге – Россиядә. Үзбәкстан, Казахстанда 700 меңгә якын милләттәшебез гомер кичерә. Украина, Белоруссиядә дә күп милләттәшләребез яши. Ерак чит илләрдә дә, хәтта Австралия белән Америкада да аларның саннары шактый. Татарстан, суверенлык юлына баскач, зур бурычларының берсе итеп, милләтебезнең бербөтен булып яшәвен билгеләде. Татарстан Президенты Шәймиевнең үз эшчәнлеген дөрес юнәлештә алып бару нәтиҗәсендә татарлар аралашып, ярдәмләшеп яши башладылар. Төрле җирләрдә яшәүче милләттәшләребез Казанны – башкалалары итеп, Шәймиевне үз Президентлары итеп кабул иттеләр. Бу Декларация кабул ителгән, референдум үткәргән көннәрдә бигрәк тә ачык күренде. Дөньяның төрле почмакларында яшәгән татарлар, аның нәтиҗәсен көтеп, төннәрен йокламый үткәрделәр. Минтимер Шәрипович исеменә бертуктаусыз телеграммалар яудырып, үзләрен референдумда катнашучылардай итеп хис иттеләр. Мондый мөнәсәбәт бүген дә дәвам итә. Нинди генә эшкә тотынса да, Беренче Президентыбыз халкыбызга көч, куәт биреп торучы шәхес булып кала бирә.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КҮҢЕЛДӘГЕ МӨҺЕР МӨҺИМРӘК

Гаилә

Бер ел эчендә илдә яңа корылган гаиләләр саны да, аерылышу очраклары да арткан. Саннар теленә күчсәк, узган елның беренче тугыз аенда гына да Россиядә барлыгы 721077 пар өйләнешкән. Бу алдагы елның шушы чоры белән чагыштырганда 140 мең очракка күбрәк. Шул ук вакытта илдә аерылышучылар саны да арткан. Узган елның тугыз аенда Россиядә 481176 гаилә таркалган. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 80 мең очракка күбрәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанда шушы ук чорда 6,73 мең гаилә (узган ел белән чагыштырганда 40 процентка күбрәк. – **Д.Г.**) төзелгән, 5,89 мең аерылышу очрагы (61,8 процентка күбрәк) теркәлгән. Хәтерләсәгез, узган елның июнь аенда Татарстан таркалган гаиләләр саны буенча ил төбәкләренең беренче унлыгына ук эләккән иде. Гаиләләр, нигездә, хыянәт, акча җиткерә алмау, ир яки хатынның хәмер белән мавыгуы кебек начар гадәтләр аркасында таркала, ди белгечләр.

Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге җитәкчесе, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова бу күренешнең тагын бер сәбәбен атый.

– Бер ел эчендә илдә бер үк вакытта яңа теркәлгән гаиләләр саны да, аерылышучылар саны да арту – коронавирус аркасында кертелгән чикләүләр нәтиҗәсе. 2020 елны өйләнешергә теләгән парларның күбесе туйларын эпидемиологик вазгыять яхшырганчы дип кичектереп торырга мәҗбүр булды. Чикләүләр аркасында ЗАГСка барып җитә алмаган, яки суд аша аерылышырга өлгермәүчеләрнең дә күбесе бу эшне киләсе елга калдырды. Шул рәвешле узган ел илдә өйләнешүчеләр дә, аерылышучылар саны да артты, – ди белгеч.

Үзизоляция чорында психолог Чулпан Нигъмәтҗановага ярдәм сорап килгән парлар саны да арткан. Парлыларның күбесе бер-берсен аңламаудан, дөньяга төрлечә караш-максат белән яшәүләре аркасында уртак фикергә килә алмауларыннан зарланган. Тәүлек буе бер түбә астында яшәргә туры килгәч, күп кенә парлар буш вакытны бергә уздыра белмәүләрен дә ачыклаган.

– Коронавируска бәйле чикләүләр аркасында гаиләләр ике төркемгә бүленде. Бер ишләре үзизоляция вакытында бер-берсен бөтенләй яңа яктан ачып, тагын да якынаеп, мөнәсәбәтләрен ныгыта төште. Бала тәрбияләүдән кала башка бернинди уртак кызыксынулары булмаган парлар исә бу чорны талашып, тавыш-гауга белән уздырды. Соңгы арада аерылышу очракларының артуы да күбрәк әнә шуның белән бәйле, – ди психолог.

Заманалар үзгәргән саен, рухи кыйммәтләр дә үзгәрә. Еллар узган саен, элегрәк башкача мөмкин түгел дип саналган күренешләргә дә мөнәсәбәт башкача була башлый. Гаилә мәсьәләсендә дә шул ук хәл. Яшерен-батырын түгел, элек-электән дәрәҗәле күренеш саналган гаилә коруга да бүген яшьләрнең күбесе җиңелчә карый. Шушы шартларда, учакка утын өстәгәндәй, гаилә тормышына кагылышлы сәер генә кануннар да гамәлгә керә тора.

Билгеле булганча, узган елның 15 июленнән Россия паспортларында гаилә хәлен, 14 яшькә кадәрге балаларны теркәү ирекле калды. Бу яңалык тирәсендә әле дә булса бәхәсләр куера. Берәүләр үзгәрешне бишкуллап хупласа, икенче берләре бу җәмгыятьтә хыянәт, азгынлык кебек күренешләрнең артуына китерәчәк, дип фаразлый. Психолог Чулпан Нигъмәтҗанова да паспортта гаилә хәлен, балаларны күрсәтүнең ирекле калуын гаилә институтын шактый какшатачак яңалык дип бәяли. «Бүген яшьләр болай да гаилә кору, аерылышу кебек күренешләргә 5 минут эчендә башкарыла торган җиңел эш итеп кенә карый. Паспортлар белән бәйле әлеге яңалык бу мөнәсәбәтне тагын да кискенләштерәчәк. Аерылышучылар саны да артачак кына», – дип фаразлый белгеч.

Чулпан Илдарханова исә башка фикердә. «Хәзерге вакытта безнең бөтен электрон документлар цифрлаштырыла. Шуңа күрә кешенең гаилә хәле, балалары бармы-юкмы икәнлекне ачыклауның да бер авырлыгы юк. Бу яңалык нәтиҗәсендә кеше үзе турында ниндидер мәгълүматны яшереп кала алыр дип куркырга кирәкми», – ди ул. Ничек кенә булмасын, бу очракта кешенең «намус» һәм «җаваплылык» дигән төшенчәләрне истән чыгармавына гына өмет итәсе кала. Күңелдәге мөһер мөһимрәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы **Заһидуллина** Алия Рәсим кызы; «Краснодар Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең конкурс идарәчесе **Кондратьев** Сергей Витальевич; «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесе инженеры **Ляукин** Владимир Михайлович; «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – корпоратив директоры **Хәлиуллина** Жанна Евгеньевна; республикада китапханә эшен үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе китапханә процессларын автоматлаштыру бүлеге мөдире **Исхаков** Тәлгать Юныс улы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Бөтендөнья татар конгрессының республика иҗтимагый фонды документлар әйләнеше бүлеге башлыгы **Кутузова** Люция Азат кызы; күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гамәли тикшеренүләр институты» аерымланган структур бүлекчәсе башлыгы **Таһиров** Морат Салих улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Хәмидуллин Дамир Минтаһир улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Хәмидуллин** Дамир Минтаһир улы; халыкны социаль яклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Хуҗина** Эльмира Габделхак кызы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе матди-техник тәэминат бүлеге башлыгы урынбасары **Гарипов** Сирин Рамил улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Древке** Татьяна Николаевна, Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Кандилов** Валерий Петрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Чаллы шәһәре һәм Тукай районы буенча муниципальара бүлеге башлыгы урынбасары **Аяпбергенов** Арман Жасулановичка, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары **Гатин** Линар Рифкать улына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дәүләт җир күзәтчелеге, геодезия һәм картография бүлеге башлыгы урынбасары **Кәримов** Илсур Рәис улына, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы документларны эшкәртү һәм исәпкә кую гамәлләрен тәэмин итү буенча 2 номерлы бүлеге башлыгы **Солтанова** Эльмира Вакыйф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Элемтә чараларының югары сыйфатлы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итүдәге казанышлары һәм намуслы хезмәте өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүмат системаларын, техник чараларны һәм элемтә каналларын эксплуатацияләү бүлеге башлыгы **Филюшин** Евгений Юрьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Зәй урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе-урманчысы **Забродина** Ирина Григорьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Вахитов районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры **Аширова** Ольга Владимировнага; Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Вахитов, Идел буе районнарындагы социаль яклау бүлеге башлыгы **Мөхәммәтшина** Галия Рәшит кызына; дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы **Тлитова** Ирина Алексеевнага, «Югары Утар психик тайпылышлары булган гражданнар өчен балалар интернат-йорты» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Гәрәев** Имаметдин Гәрәй улына; Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең социаль эш һәм югары белемле шәфкать туташлары әзерләү факультеты деканы, икътисад теориясе һәм социаль эш кафедрасы мөдире **Максимова** Маргарита Николаевнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:15:140101:3, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Верхнеуслонский муниципальный район, д. Новое Русское Маматкозино, ул. Луговая, д. 2, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка.
Заказчик: Босецкий Игорь Валентинович, адрес: Респ. Татарстан, г. Казань, ул. Чуйкова, д. 89, кв. 190, тел.: +79173930228.
Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 22 февраля 2022 г. в 9 часов 00 минут по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Верхнеуслонский муниципальный район, д. Новое Русское Маматкозино, ул. Луговая, д. 2.
Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (Тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.
Смежный земельный участок, с правообладателями которого требуется согласовать местоположение границ: 16:15:140101:43, расположен в Республике Татарстан, Верхнеуслонский муниципальный район, Новорусско-Маматкозинское сельское поселение, д. Новое Русское Маматкозино, ул. Луговая.
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ

Кадастровым инженером Каримуллиным Русланом Даниловичем (СНИЛС 103-594-068 40, квалификационный аттестат №16-11-168, свидетельство СРО АКИ «Поволжье» № 0157 от 03.08.2012 года, почтовый адрес: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д.14; моб. тел.: 89050220041, e-mail: vgora.rti@mail.ru) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:19:000000:668, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Заинский муниципальный район, СПК «Савалеево». Заказчиком кадастровых работ является Варламов Евгений Александрович (423520, РТ, Заинский район, г. Заинск, ул. Ялчыгола, д. 6, кв. 29, тел.: 89534097210). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 16.00 ч. по адресу: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д.14. Также с проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 8.00 до 12.00 ч. по адресу: 423520, РТ, Заинский район, г. Заинск, ул. Ялчыгола, д. 6, кв. 29, тел.: 89534097210. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 422701, РТ, с. Высокая Гора, ул. Полковая, д.14.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Әгерҗе районы Девятерня авылында яшәүче яраткан әниебез, әбиебез, әтиебезнең сөекле тормыш иптәше **МОРАТОВА Галия Габдулла кызының** 19 гыйнварда олы юбилее – 60 яшь тулган көне.

Кадерлебез, сине гомер бәйрәмең белән ихластан котлап, ныклы сәламәтлек, имин, бәрәкәтле, тигез тормыш, чиксез шатлыклар телибез! Тәпле киңәшләрең, җылы сүзләрең, нурлы йөзең өчен мең рәхмәт!

«Котлы булсын!» – дибез синең
60 яшең тулган көнең.
Өй түрләрең көләп торсын,
Туганнар гел килеп торсын.
Ут уйнаткан унган кулың
Талчыгуны белмәсен.
Кайгы-хәсрәт сагышлары
Йортыбызга кермәсен!

Барлык туганнар исеменнән, сине яратып, әтиебез Камил, кызың Рамилә, киявең Эдуард, оныкларың Кәрим, Ралинә һәм Эльдар

Спорт

Пекинга кемнәр бара?

Кышкы Олимпия Уеннары башланырга өч атнадан азрак вакыт калды. Әлегә бу ярышларда чыгыш ясаячак спортчылар исемлегендә Татарстаннан бер генә кеше бар.

Чаңгыда берәү генә калды

Узган ел октябрь ахырында Россия Олимпия комитеты Олимпиадага барырга мөмкин спортчыларның исемнәрен атады. 599 кешелек исемлеккә Татарстаннан 20 спортчы керде. Әмма инде хәзерҗән үк аларның саны азрак буласы билгеле. Әйтик, чаңгычылар исемлегендә республикадан 5 кандидат бар иде. Христина Мацокина, Анна Нечаевская, Андрей Ларьков, Артем Николаев һәм Антон Тимашов арасыннан бары Христина гына төп командага эләкте. Калганнары исә илнең иң шәп чаңгычылары сафында Россия даның якларга лаек икәнлекләрен расдый алмады. Безнекеләргә үз көчләрен күрсәтергә коронавирус белән авыру да комачау итте.

Христина Мацокинага – 23 яшь. Тумышы белән ул – Магадан өлкәсеннән. Сүз уңаеннан, Россиянең Чаңгы узышлары федерациясе президенты Елена Вяльбеның якташы. Соңгы елларда Татарстан данын яклый. Дүрт ел элек узган Олимпиадага бездән Андрей Ларьков белән Анна Нечаевская барып, икесенә өч медаль – бер көмеш һәм ике бронза алып кайтканнар иде.

Галимовка ни булган?

Пекинга баруы ихтимал спортчылар исемлегенә «Ак барс»та чыгыш ясаучы 9 хоккейчы кергән иде. Ул вакытта аларның җыелма команда составына эләгү мөмкинлеге бик аз дип саналды. Ник дигәндә, төп игътибарны НХЛда чыгыш ясаучы егетләргә бирергә җыендылар. Әмма океан артындагы лиганың түрәләре, коронавирустан куркып, үз уенчыларын Олимпиадага җибәрмәү турында карар кабул итте. Шулай итеп, командаңы КХЛда, ягъни үзебездә уйнаучылардан туплыйлар. Шуңа да карамастан, киңәйтелгән составка «Ак барс»тан нибары өч егет – капкачы Тимур Билалов, һөҗүмчеләр Артем Галимов белән Дмитрий Воронков кына эләкте.

Бу әле алар Пекинга барып җитә диган сүз түгел. Исемлек тагын 11 кешегә кыскарачак. Дмитрий Воронковның әле күптән түгел генә савыгып искә алу урынлы булыр. Атна ахырында исә Артем Галимовның җыелма командага барудан баш тартуы турындагы хәбәрләр игътибарны җәлеп итте. Ике төрле мәгълүмат булды. Берәүләргә ышансаң, һөҗүмче төп составка эләгә аласына ышанмый, шуңа күрә әзерлек өчен Мәскәүгә барып йөрергә теләмәгән. Икенчеләре исә егетнең гаиләсендә мәшәкать килеп чыкканын җиткерде, шуңа күрә башланда хоккей кайгысы түгел икән. Ахыр чиктә барысы да хәл ителгән, Артем Галимовның җыелма командага барасын әйтеләр.

Камиләдән медаль көтәбез

Олимпиадада Казан кызы Евгения Тарасова да чыгыш ясар диган өмет бар. Илнең Фигуралы шуу федерациясе Пекинга барасы спортчылар исемлеген әлегә игълан итмәсә дә, Евгениянең иптәше Владимир Морозов белән җыелма команда составына керәсе шик уятмый. Узган атна ахырында алар Европа чемпионатында парлы шууда көмеш медаль яулады. Билгеле булганча, Тарасова белән Морозов 2018 елгы Олимпиадада икенче урынны алган иде.

Казанда туып-үскән Камилә Вәлиева Таллинда Европа чемпионы исемен яулап, Пекин Олимпиадасында җиңүгә төп дәгъва кылучы икәнен күрсәтте. 15 яшьлек кызның җиңүе белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та котлады. Камилә бу сезонда Гран-при ярышларының ике этабын отты, Россия чемпионы булып танылды. Инде менә Европа чемпионатында җиңү яулады. Әлеге ярышларда 9 мәртәбә дөнья рекордын яңартты. Таллинда бер мәртәбә алгышыга дучар булды, әмма әлеге хата Пекинга яхшырак әзерләнергә этәргеч булачак. «Олимпия Уеннарына элегүем белән бик бәхетле мин. Бу хакта һәр спортчы хыялланa. Олимпиадага бару үзе үк – зур уңыш», – диде Камилә «Матч ТВ» каналы хәбәрчесенә. Хәтерләсәгез, Пекин Олимпиадасында Россия спортчылары ике алтын медаль откан, шуның берсен – хоккейчылар, икенчесен исә фигуралы шууда татар кызы Алинә Заһитова яулаган иде.

Илнар ХӘСНУЛЛИН

ЯРАЛЫ МӘХӘББӘТ

Суд залыннан

Танышларым арасында катнаш гаиләләр шактый. Бернинди каршылыкларга карамыйча, бәхетле яшәүчеләре дә аз түгел, әлбәттә. Әмма тормышта башка төрле каршылыклар да очрый тора. Тел, гореф-гадәт – бер хәл, дини сораулар да кушылса, хәл шактый катлаулана. Ике арага ир белән хатынның туганнары, якыннары, балалары да керсә... Менә тагын бер гаилә язмышы шундый аяныч фаҗигагә килеп җиткән... Бабай булган кеше киявенә пычак күтәргән.

Югары Осланда туып-үскән Николай Самойлов бала чагыннан ук диңгезче булырга хыяллана. Җәйләре Иделдә узган егетнең Казан елга техникумына укырга керүе, аннан соң армиядә диңгез флотында хезмәт итүе дә яшьлек хыялы белән бәйле.

Казан елга портына эшкә урнашып йөргән көннәрендә ул булачак тормыш иптәше – Казанның бер хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшләүче Алевтина белән таныша. Бер елга якын дуслашып йөргәннән соң, һәр ике якның ризалыгын алып, гөрләтеп туй итәләр. Тормышлары һәр яктан җитеш. Олы кызлары Светлана үз гаиләсе белән яши. Оныклары Алинага – 6, Альбертка – 4 яшь. Үз янындагы уллары – югары уку йорты студенты. Кыскасы, булганына шатланып, һәр нәрсәнең кадерен белеп кенә яшисе дә бит.

Казанның Вахитов районы ачык суд утырышы барышында, таза гәүдәле 44 яшьлек бу ир-атка карап, аның кеше үтерергә теләвенә ышанасы да килми. Югыйсә гомерен яраткан хезмәтенә багышлаган ике бала әтисе. Эшеннән бирелгән характеристикадан күренгәнчә, хезмәт алдынгысы, төрле җәмәгать эшләрендә башлап йөрүчеләрдән санала. Төрле яклап яхшы яктан гына искә алынучы гаилә башлыгының мондый адымга баруына гаҗәпләнәсе генә кала. Чит кешенең күңеле – кара урман, дип белми әйтмиләрдер шул инде.

Бердәнбер кызының ирен үтерел, нәрсә исбатламакчы булган? Үзләре дә берсеннән-берсе кечкенә ике бала үстерүче киявен берничә җирдән бугазын яралавы, тәнендә тугыз җирдә тирән җәрәхәт салуының бик җитди сәбәпләре дә булырга тиештер бит инде.

Суд барышында мәсьәләнең башлыча хокукый ягы каралса да, анда гыйбрәт алырлык хәлләр шактый булды. Һәрхәлдә, суд узды дип тынычланырга бик иртә икәнлеге көн кебек ачык иде.

Узара ызгыш-талаш вакытында чактан гына исән калган Әмир Хисмәтуллинның әнисе кияү белән каената арасындагы низагны үзенчә аңлата.

– Ишерен-батырын түгел, Николай булачак киявен башта ук өнәп бетермәде. Яшьләр бер-берсен яраткач, без дә берни эшли алмадык. Светлана да әүлия түгел, әмма без яшьләр арасына кысылмадык. Кызлары тугач, исемне үзләренчә куйдылар. Кода белән кодагыйның Алинаны чиркәүгә алып барып чукындырып кайтулары да соңыннан гына беленде. Юкса, безнең дә үз динебез бар. Улыбыз Әмир баштарак күп нәрсәгә юл куя килде. Кызының муенына алтын тәре таккач та түзде. Инде менә оныгыбыз Альбертны сөннәткә утыртырга каршы килуләренә чыдый алмады, ахры. Шуның аркасында әледән-әле тавыш чыга. Күпме кешедән ишеткәнем бар: катнаш гаилә тамыры җәрәхәтле гөл сыман. Улым да чактан гына үлемнән калды. Ярый әле моның белән генә бетсә, – ди Әмирнең әнисе Язилә ханым күз яшьләре аша.

Николай Самойлов әйтүенчә, 19 сентябрьдә аларны кызлары Светлананың туган көненә чакыралар. Эш көне була. Соң гына киләләр. «Эштән соң дуслар белән бераз мәҗлес тә корып алган идек», – ди Николай. Баштарак матур гына утыралар. Сүз иярә сүз китеп, Әмир белән Светлана уллары Альбертны сөннәткә утыртырга мәсьәләсендә ызгышып алалар. Ир белән хатын ачуланышырлар да, татуланышырлар да. Әмма ызгышка өлкәннәр дә кушылып китә. Әмир дә үз сүзен кистереп әйтә. «Кызымның башын бутадыгыз, инде хәзер улымнан урыс ясарга бирмим», – ди. Үзара тынычлык беткәч, өлкәннәр кечкенә балаларны алып, таралыша ук башлый. Өйдә бары тик Николай һәм Әмир генә кала. «Хәлләр аеруча куркыныч төс алгач, мин улым белән ваннага кереп бикләндем», – ди Светлана.

Әмир кызганнан-кыза баручы Николайны берничә тапкыр тынычландырырга тырышып карый. «Бу – безнең гаилә эше. Үзебез хәл итәрбез», – ди. Әмма кунакка шактый кызмача килгән Николайны тынычландыра алмыйлар. «Мин сине барыбер үтерәм», – дип янавын күршеләр дә ишетә. Өч сәгатькә якын сузылган ызгыш-талаш чактан гына үтереш белән тәмамланмый кала.

Полиция хезмәткәрләре әйтүенчә, Девятаев урамында «пычак белән җәрәхәтләү һәм үтерү белән янау» турында хәбәр кичке 11дә алына. Полициягә хәбәр иткәнне белгәч, Николай өенә кайтып китә. Аны полиция бүлегенә фатирыннан алып китәләр.

Тән ярасы әкренләп булса да төзәлә. Әмирнең бугазы тирәсендәге яралар да инде беленми диярлек. Суд барышында Николайның берничә тапкыр гафу үтенүе, Әмирнең исә «тәнемне үзем яраладым» диюе дә гаепләнүчене иреганнан мәхрүм итмәсеннәр өчен әйтелде булса кирәк.

Гаепләнүченең моңарчы җинаять кылмавын, эш урыныннан уңай характеристика бирелүе, өлешчә гаебен тануын һәм каршы якның үтенечен исәпкә алып, Россия Федерациясе Җинаять кодексының 307–309 маддәләре нигезендә Казанның Вахитов районы суды Николай Самойловны 1 ел да 6 айга иреганнән мәхрүм итү турында карар кабул итте.

Камил СӘГЪДӘТШИН

СИНЕ ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР

ЕЛ САЕН РОССИЯДӘ 30 МЕҢНӘН АРТЫК БАЛА ЮГАЛА

Узган атнада Татарстанда югалган ике бала, шөкер, исән-сау табылды. Ләкин бу очраклар сабыйлары өчен болай да коты очып торган әти-әниләрне кабат борчуга салды. Балаң өйгә кайтмаса, нишләргә? Бу һәм башка сорауларга белгечләр белән җавап эзләдек.

Узган атнада Татарстанда югалган ике бала турында ишетми калганнар юктыр. Казанда 13 гыйнварда өеннән чыгып киткән 10 яшьлек малайны 14 гыйнварда гына эзләп таптылар. Чаллыда исә 11 яшьлек малайны 3 көн буе эзләделәр.

Сан

«ЛизаАлерт» эзләү-коткару отряды мәгълүматларына караганда, **2021** елда алар Татарстанда балалар югалу очракларына бәйле **167** (**104** малай, **63** кыз бала) гаризага кабул иткән. Отряд волонтерлары **153** сабыйны исән-сау килеш тапкан. 6 очрак әлегә кадәр расланмаган, табылган **3** баланың якыннарын эзләләр (мондый очракларда балалар полиция хезмәткәрләре, битараф булмаган кешеләр кылдырган гаризалар буенча эзләнә һәм табыла. Соңыннан ул сабыйларның якыннарын эзли башлыйлар). **4** сабыйның мәетен генә таба алганнар, ә берсен бөтенләй тапмаганнар. Югалу очракларының **95** проценты шәһәрләргә туры килә.

Ни сәбәпле кайтмыйлар?

Белгечләр өйгә кайтмаучыларны шартлы рәвештә ике төркемгә бүлә. Беренчеләре (гадәттә, үсмер яшьтәгеләр) мондый адымга аңлы рәвештә бара. Икенчеләре я адаша, я начар кеше кулына эләгә.

Балалар психологы Галия Гыймадиева сүзләренчә, әти-әни баласының аңлы рәвештә өйгә кайтмавын бер генә хәлгә, сүзгә, сөйләшүгә бәйләп ялгыша.

– Күп очракта балалар өйдә бер-бер хәл булса, әти-әнисе белән мөнәсәбәтләр начарайса, чыгып китә. Башка җирдә яхшырак – алар әнә шулай уйлый. Икенче еш очрый торган сәбәп – баланы артык кайгырту (гиперопека). Әти-әнисе артык кайгыртучан булса, баланың гаиләдән аерылып чыгып, үзен зурлар дөньясында сынап карыйсы килә. Якыннарыннан башка яши алырмы? Ул шушы сорауга җавап һәм мажара эзли башлый. Шуңа да кайгыртучанлык һәм ирек, мөстәкыйльлеккә өйрәтү ата-ана тарафыннан бер дәрәҗәдә бирелергә тиеш. Баланс булсын, – дип сөйли белгеч. – Бер сөйләшү белән генә балага нидер төшендереп, араларны җылытып яки суытып булмый. Балагызны артык еш сүгәсез икән – ул үзен чит кеше итеп тоячак, мине монда яратмыйлар икән, дип уйлаячак. Нәтиҗәдә үзе үк сездән читләшәчәк. Үз-үзегезне аның янында ничек тотасыз – шуңа игътибар итегез. Бәхетле була беләсезме? Юк икән, балагыз да үзен бәхетле итеп тоя алмаячак.

Соңарганчы...

Һәр әти-әни баласы өчен ут йотып тора. Мәктәпкә киткән җиреннән кайтмаса? Начар кешегә ияреп, балагә юлыкмасмы? «ЛизаАлерт» белгечләре әти-әниләргә түбәндәге киңәшләргә колак салырга куша:

✓ балагызга тышкы кыяфәт буенча гына язып кешене начарыннан аерып булмавын аңлатыгыз. Таныш булмаган кеше ни генә әйтсә дә, «юк» дип җавап бирергә өйрәнсен;

✓ балагызны кешедән ярдәм сорарга читенсенмәскә, курыкмаска өйрәтегез. Шулай ук ярдәмне кемнән сорарга кирәклеген дә тәгаенләгез. Бала җитәкләгән әни, полиция хезмәткәре, каравылчы, сатучы, кассир...

✓ балагыз белән һәрвакыт элемтәдә торыгыз. Әгәр ул берәр каян кайта икән, алдан сезгә шалтыратсын. Ләкин шуңа игътибар итегез: мондый шалтыратуларның бала чиктән тыш контроль түгел, ә бер-берең өчен борчылу буларак кабул итәргә тиеш;

✓ балагызны каты итеп кычкырырга өйрәтегез. Гадәттә, әти-әниләр балаларына тыныч булырга, башкаларга комачауламаска куша. Шуңа да, куркыныч янаганда, балалар эндәшми. Белеп торсын: адашса да, башка кеше тарафыннан агрессия сизсә дә, ул кычкырырга тиеш;

✓ балагыз мәктәптән кайтырга гадәтләнгән сукмакны үз күзләрегез белән барып күрегез. Ул нинди йортлар, гаражлар, караңгы почмаклар аша үза – игътибар белән карагыз. Шикләнәсез икән, аңа якты, кеше күп йөри торган юлдан кайтырга кушыгыз;

✓ виртуаль дөньясызы яши алмаучы буын интернеттагы куркынычсызлык кагыйдәләрен дә яшьтән белеп торырга тиеш. Балагызга фотоларын һәм үзе турындагы мәгълүматны бик саклык белән генә «әләргә» кирәклеге аңлатыгыз. Аратира аның «виртуаль дус»ларын тикшереп торсагыз да була. Бигрәк тә алар арасындагы өлкән яшьтәге кешеләргә игътибар итегез;

✓ балагызны һәрдаим фотога төшерегез. Югалганнарны эзләгәндә яңа төшерелгән фото – бик әһәмиятле нәрсә. Шулай ук аның иртән нәрсә киеп чыгып китүенә дә игътибар итәргә тырышыгыз. Стресс аркасында, баласын югалткан әти-әниләр эзләүчеләргә бу мәгълүматны тиз генә әйтә алмый. Бик курыксагыз, аны һәр иртә фотога төшерү дә комачауламас;

✓ балагызның телефонын үзегезнең исемгә рәсмиләштерегез. Кирәклә операторанның кемгә һәм кайчан шалтыратканы турындагы мәгълүматы телефон теркәлгән кешегә генә бирә;

✓ заманча гаджетлар һәм төрле программалар барлыгын да онытмагыз. Хәзер смартфоннарга кирәк кешенең GPS-локаторын (ул икенче кешенең телефоны кайсы урында булуын күрсәтә) урнаштырырга мөмкин. Шулай ук алар өчен GPS-трекер янсә махсус беләзек тә сатып алырга мөмкин.

Галия Гыймадиева тагын бер нәрсәгә аеруча игътибар итәргә киңәш итте:

– Югалган балагызны тапискансыз икән, ачу, куркy кебек эмоцияләрне читкә куеп торыгыз. Балагызга елмаегыз, аны кочаклагыз, ничек яратуыгызны әйтегез. Бала үзен сезгә кирәк, кадерле итеп тоярга тиеш. Тырышсагыз, мондый куркыныч, авыр мәсьәләне дә уңай хәл итәргә мөмкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әгәр якыннарыгыз югалган икән, «ЛизаАлерт» коткару отрядының **8-800-700-54-52** номерлы «кайнар линия»сенә шалтыратыгыз. Шалтырату бушлай. Гаризалар Россиянең барлык төбәкләреннән дә кабул ителә.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7043 данә
Гомуми тираж – 18156 данә

Газетага сертификат биреләде Заказ 206

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Вакыл сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+